ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

площадь Советская, д.12, г.Арск, 422000

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Совет мәйданы, 12 нче йорт, Арча шәһәре, 422000

Тел. (84366)3-00-44, факс (84366)3-11-44. E-mail: archa@tatar.ru. www.arsk.tatarstan.ru

# КАРАР

11 ноябрь 2024 ел № 828

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы территориясендә барлык милек рәвешләрендәге спорт инфраструктурасы объектларын инвентарьлаштыру тәртибен раслау турында**

"Татарстан Республикасы территориясендә барлык милек рәвешләрендәге спорт инфраструктурасы объектларын инвентарьлаштыру турында" 2024 елның 29 февралендәге 86 номерлы Татарстан Республикасы Спорт министрлыгы боерыгы нигезендә, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы милкендәге спорт инфраструктурасы объектларын инвентарьлаштыру максатыннан карар бирәм:

1 Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының спорт инфраструктурасы объектларын инвентарьлаштыру тәртибен (алга таба -Тәртип) кушымта нигезендә расларга (1нче кушымта);

2. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының спорт инфраструктурасы объектларын инвентарьлаштыру вакытын елга бер тапкыр билгеләргә.

3. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы территориясендә барлык милек рәвешләрендәге спорт инфраструктурасы объектларын инвентарьлаштыру буенча комиссия төзергә һәм составын расларга (2 нче кушымта).

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга һәм Арча муниципаль районының "Интернет" челтәрендәге рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге башлыгы Ә.Р. Вәгыйзовка йөкләргә.

Җитәкче Р.М.Гатиятов

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
ИНН 1609009516

Арча муниципаль районы
Башкарма комитетының
11.11.2024г ел, №828
карарына 1 нче кушымта

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының спорт инфраструктурасы объектларын инвентарьлаштыру тәртибе**

Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының мәгариф оешмаларының тиешле инфраструктурасын да кертеп, спорт инфраструктурасы объектларының фактта булуын ачыклау, аларны исәпкә алу, физкультура-спорт юнәлешендәге матди-техник базаның торышын билгеләү, спорт объектларыннан файдаланудагы хокук бозулар, нәтиҗәсез файдалану һәм билгеләнеше буенча файдаланмау фактларын ачыклау максатында эшләнде.

2. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының спорт инфраструктурасы объектларын инвентарьлаштыруның әлеге тәртибе Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының спорт инфраструктурасы объектларын инвентарьлаштыру тәртибен билгели.

3. Оештыру-хокукый рәвешләренә карамастан, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы территориясендә урнашкан, укыту-күнекмә һәм физкультура-савыктыру дәресләре, спорт чаралары өчен билгеләнгән, гамәлдәге, реконструкцияләнүче һәм капиталь ремонтланучы спорт инфраструктурасы объектлары инвентарьлаштырылырга тиеш.

4. Инвентарьлаштыру уздырганда комиссия түбәндәгеләрне гамәлгә ашыра:

- инвентарьлаштыру объектларының хуҗаларының һәм кулланучыларның хокукларын раслый торган документларның булуын тикшерү;

- спорт объектының документлары булуын тикшерү (инвентарьлаштыру объектын исәпкә кую документлары булу: объектны эксплуатациягә кертү актлары, техник паспортлар; объектны арендага тапшыру документлары һәм башкалар);

- ябык һәм ачык инвентарьлаштыру объектларын карау һәм паспортларның, исәпкә кую карточкаларының булуын тикшерү.

5. Инвентарьлаштыру объектларын исәпкә кую бланкларыннан мәгълүмат исемлеккә исемнәре һәм тиешле бүлекләре буенча кертелә. Инвентарьлаштыру объектларының исемлеге электрон рәвештә алып барыла.

6. Хокук бозу фактлары, спорт объектларыннан нәтиҗәле файдаланмау һәм билгеләнеше буенча файдаланмау фактлары ачыкланган очракта, комиссия файдаланудан чыгарылган, файдаланудагы капиталь ремонт (реконструкция) үткәрүгә мохтаҗ инвентарьлаштыру объектларын, аларны эксплуатациягә тапшыру датасын һәм әлеге хәлгә китергән сәбәпләрне күрсәтеп, аерым исемлеккә кертә. Әлеге объектлар шулай ук гомуми инвентарьлаштыру исемлегендә күрсәтелергә тиеш. Теләсә нинди үзгәрешләр ачыкланганда (яңа ачыкланган объект, объектның милекчесе алмашыну, объектның матди-техник халәте үзгәрү, объектны куллануның билгеләнеше үзгәрү һ.б.) объектка яңа паспорт яисә исәпкә кую карточкасы тутырыла, әлеге мәгълүмат

инвентарьлаштыру исемлегенә кертелә һәм кичекмәстән Татарстан Республикасы Спорт министрлыгына җиткерелә.

7. Инвентарьлаштыру йомгаклары буенча Татарстан Республикасы Спорт министрлыгына комиссия тарафыннан инвентарьлаштыру объектларының исемлеге тапшырыла.

Арча муниципаль районы
Башкарма комитетының
11.11.2024г. ел, № 828
карарына 2 нче кушымта

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы территориясендә барлык милек рәвешләрендәге спорт инфраструктурасы объектларын инвентарьлаштыру комиссиясе**
**СОСТАВЫ**

| | |
|---|---|
| Гатиятов Ренат Мансурович | Комиссия рәисе, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе; |
| Комиссия әгъзалары: | |
| Вәгыйзов Әмир Рөстәмович | Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге башлыгы; |
| Сираҗиев Илһам Гаптелнурович | Арча муниципаль районының мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы җитәкчесе (килешү буенча); |
| Хәсәнов Илнур Мәхмүтович | Арча муниципаль районы Башкарма комитетының инфраструктура үсеше бүлеге башлыгы; |
| Әюпов Илфар Илдарович | Арча муниципаль районы Башкарма комитетының "Мәдәният идарәсе" МУ башлыгы (килешү буенча); |
| Мөхәмәдияров Рамил Данилевич | Арча муниципаль районы Башкарма комитетының "Мәгариф идарәсе" МУ башлыгы (килешү буенча); |
| Кирәк булганда, комиссия утырышына спорт объектларының милекчеләре (хокук ияләре) чакырыла (килешү буенча). | |

Татарстан Республикасы
Арча муниципаль районының
спорт инфраструктурасы объектларын
инвентарьлаштыру тәртибенә кушымта

# ИСӘПКӘ КУЮ КАРТАСЫ

**Спорт объекты турында мәгълүмат**
"___" _____________ ___елга торышы буенча

Инвентарьлаштыру объектының идентификация номеры:_______________________________
1. Спорт корылмасының исеме: _______________________________________
2. Спорт корылмасының урнашкан урыны: _______________________________________
2.1. Республика, край, өлкә: _______________________________________________
2.2. Район, шәһәр: ________________________________________________________
2.3. Урам, йорт номеры: ___________________________________________________
2.4. Корпус, төзелмә: ____________________________________________________
3. Спорт төрләре буенча спорт корылмасының специальләшүе: ____________________________________________________________________________
____________________________________________________________________________
4. Спорт объектының гомуми мәйданы: _______________________ кв.м.
5. Спорт объекты урнашкан җир кишәрлегенең гомуми мәйданы: ___________________ кв.м.
6. Корылмалар буенча спорт объекты составы: (күләме, БТИ паспортының экспликация мәйданы): __________________________________________________________
7. Җир кишәрлегенең кадастр (шартлы) номеры: _____________________________
8. Җир кишәрлегеннән файдалану хокукы: ____________________________________
9. Спорт объектын эксплуатациягә тапшыру елы: ________________________ ел
10. Спорт корылмасының бәя характеристикалары:
10.1. Объектның баланс бәясе: ____________________________________ мең сум
10.2. Объектның калган бәясе: ____________________________________ мең сум
11. БТИ паспортын бирү датасы һәм номеры: "_____" _______ ел, N ___
12. Спорт объектының баланс тотучысы (тулы һәм кыскартылган исеме):
____________________________________________________________________________
13. Оешма - спорт объектының баланс тотучысы турында белешмәләр:
13.1. Почта индексы: ______________________________________________________
13.2. Республика, край, өлкә: _____________________________________________
13.3. Район, шәһәр: _______________________________________________________
13.4. Урам, йорт номеры: _______________________________________
13.5. Корпус, төзелмә: _____________________________________________________
13.6. Җитәкченең ФИАи, вазыйфасы: __________________________________________
13.7. Федераль мөлкәт реестрына оешманы кертү турында таныклык
"_____" ____________ ел, N ____________________
13.9. СООГУ/ОКОГУ коды (югарырак орган): _________________________________
14. Спорт объектын баланска кабул итү-тапшыру акты датасы һәм номеры
"_____" ____ ел, N ______________________________________
15. Оешманың спорт объектына дәүләт теркәве турында таныклыкка ия булу хокукы:___________________________________________________

16. Спорт объектына ия булу хокукын билгеле торган документның исеме, датасы һәм номеры: "____" ________ ел, N __________

Комиссия рәисе: ________________________________________________________(________________)

Рәис урынбасары: ____________________________________(_______________________)

Комиссия секретаре: _________________________________ (______________________)

Комиссия әгъзалары:

_________________________________________________ (_______________________)

___________________________________________________(_______________________)

___________________________________________________(_______________________)

___________________________________________________(_______________________)

___________________________________________________(_______________________)

___________________________________________________(_______________________)